СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2019 Әгерҗе шәһәре № 40-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2009 елның 3 апрелендәге 36-3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мактаулы гражданины» исемен бирү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Коррупциягә каршы экспертиза һәм норматив хокукый актлар проектлары турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2009 елның 3 апрелендәге 36-3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мактаулы гражданины» исемен бирү турындагы нигезләмәгә 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«20. Район Советы карары буенча гражданин, суд карары законлы көченә кергәннән соң җинаять кылган өчен, «Мактаулы гражданин» исемен, таныклыгын һәм медаленнән мәхрүм ителергә тиеш».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ